КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 март г.Казань № 166

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 16 февраль, 47 нче; 2007 ел, 14 июнь, 235 нче; 2008 ел, 26 ноябрь, 832 нче; 2009 ел, 27 февраль, 115 нче; 2009 ел, 8 апрель, 209 нчы; 2009 ел, 21 август, 571 нче; 2010 ел, 2 апрель, 229 нчы; 2015 ел, 4 февраль, 61 нче; 2015 ел, 12 март, 146 нчы; 2016 ел, 13 май, 305 нче; 2016 ел, 26 май, 359 нчы; 2016 ел, 19 октябрь, 762 нче; 2018 ел, 15 февраль, 90 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә, 7 нче пунктны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«7. Министрлык, агымдагы елның 1 мартыннан (2018 елда – 1 апреленнән) да соңга калмыйча, чираттагы финанс елына һәм план чорына федераль бюджет турындагы федераль законда Татарстан Республикасы бюджетына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бу Нигезләмәнең 4 нче пункты белән билгеләнгән гражданнар – субсидия алучылар чираты тәртибендә субсидия бирелгән гражданнарның бу Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтадагы форма буенча исемлекләрен (алга таба – исемлекләр) төзи һәм аларны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына җибәрә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин